**ТАТАСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Югары Колчурино авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Верхнеколчуринского**
**сельского поселения**
**Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422873, РТ, Әлки районы, Югары Колчурино авылы, 8 Март ур., 21
Телефон (84346)78014

Адрес: 422873, РТ, Алькеевский район, с. Верхнее Колчурино, ул. 8 Марта, д. 21
Телефон (84346) 78014

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2015 елның 10 феврале 3№

Югары Колчура авыл җирлеге башлыгының «2014 елда Югары Колчура авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2015 елга бурычлар турында» хисабы.

Югары Колчура авыл җирлеге башлыгы Е.В. Краснованың «Югары Колчура авыл җирлеге башлыгы хисабы 2014 ел йомгаклары буенча башкарылган эшләр турында»докладын тыңлап фикер алышканнан соң
Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Югары Колчура авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. Югары Колчура авыл җирлеге башлыгының «2014 елда Югары Колчура авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2015 елга бурычлары турында» хисабын игътибарга алырга.
2. 2014 ел йомгаклары буенча Югары Колчура авыл җирлеге башлыгы эшен канәгатьләнерлек дип санарга.
3. Халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүне алга таба да мөһим бурыч дип санарга, моның максатларында нәтиҗәле чаралар күрергә:
   - халыкны эш белән тәэмин итү һәм җирлекләрнең икътисадын ныгыту максатларында, район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән берлектә, 2011-2015 елларга кабул ителгән авыл җирлекләре территорияләрен социаль-икътисадый үстерү программасын эзлекле рәвештә үтәүне дәвам итәргә;
   - стабильләштерү финанс хәле өчен җылылык һәм энергетика ресурсларын экономияле файдаланырга, чыгымнарны оптимальләштерү буенча максатчан эшне дәвам итәргә һәм салымнарны тулысынча җыюга ирешергә.
   - шәхси ярдәмче хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен шартлар тудыру, авыл халкына җитештерелгән продукцияне сатарга ярдәм итү, хуҗалыкларда терлекләрнең баш санын арттыруга ирешү, гаилә фермалары төзүдә шәхси хуҗалыкларга һәрьяклап ярдәм күрсәтү.
   - авылда кече эшкуарлык шартлары тудырырга һәм халыкны эшкуарлыкны үстерү буенча Россия һәм республика программаларында актив катнашуга җәлеп итү буенча агитация-аңлату эшләре алып барырга.

- урыннарда әхлакый, физик тәрбияне яхшырту, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкның ялын оештыру буенча максатчан эш алып барырга,
- халыкка нәтиҗәле һәм сыйфатлы медицина ярдәменнән файдалануны арттыру, балалар авырулары профилактикасын үткәрү чараларын күрергә;
- авылда ял итүне, массакүләм спорт һәм физкультура-савыктыру эшен оештыру өчен шартлар тудырып, мәдәниятне, балалар һәм яшьләр мәгарифен алга таба үстерүне тәэмин итәргә;
- хәйрия эшчәнлегенә ярдәм итү һәм аны үстерү буенча гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;
- хокук бозуларны профилактикалау буенча халыкны, иҗтимагый оешмаларны җәлеп итеп, профилактик эшнең нәтиҗәле формаларын эшләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

Югары Колчура авыл җирлеге Советы Рәисе: Е.В.Краснова